# Иң бәхетле балалар.

1.Яллар җитсә авылларга
Кайтасы килеп тора.
Әби-бабай безне көтеп,
Тыпырдап биеп тора.

Куш.-та
Нинди рәхәт әбиемнең
Кочаклап алулары.
Бабаемның сөя-сөя
Аркамнан кагулары!

2.Бабаем мунча өлгертә,
Тәм-том пешерә әби.
Мин дә аларга булышам,
Көчемне һич җәлләми.

3.Кунакчыл авыллар барда
Читтә торсын калалар.
Әби-бабайлы буладыр,
Иң бәхетле балалар!